**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422613 п.с/за им. 25 Октября,
ул.Центральная, д.7А
тел: 8(84378) 3-54-22

**ГЛАВА АЛЕКСАНДРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422613 п.с/за им. 25 Октября,
ул.Центральная, д.7А
тел: 8(84378) 3-54-22

---

**2021елның 23 марты** **1 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының
Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында гавами тыңлаулар
билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Александр авыл җирлеге Уставының 20 статьясы белән, Александр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Александр авыл җирлеге Советының карарлар һәм карарлары проектлары буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында халык тыңлауларын 2021 елның 27 апрелендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз, Үзәк урам.7А йорт адресы буенча Александр авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз, Үзәк урам, 2021 елның 26 апреленә кадәр.

3. Җирлекнең башкарма комитетына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында гражданнарның гавами тыңлаулар уздыруны, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә..

4.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында әлеге карарны игълан итәргә:

- 25Октябрь исемендәге совхоз, Үзәк урам 7А йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендта.
- «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru. адрес буенча.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Александр авыл җирлеге
Советы рәисе**: **И.А.Бандурова**